ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 03.06.2024 **КАРАР**
753

Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм сәләтле балаларга адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү буенча комиссия төзергә (2 нче кушымта).
3. Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү комиссиясе турындагы Нигезләмәне расларга (3 нче кушымта).
4. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы башлыгы стипендиатларын билгеләү турында» 2011 елның 21 апрелендәге 259 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
5. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен

финанслауны Алабуга муниципаль районы бюджеты исәбеннән тәкъдим итәргә.

6. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазифаларын башкаручыга, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасын куллану һәм Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы аша социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.
7. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 3 июнендәге
753 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү турында Нигезләмә**

1. Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясе (алга таба текст буенча - Стипендия), интеллектуаль эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының сәләтле балаларына адреслы ярдәм күрсәтү максатыннан гамәлгә ашырыла.
2. Гомуми белем бирү оешмалары укучыларына стипендияне билгеләү, бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга - Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү буенча комиссия карары нигезендә елына бер тапкыр билгеләнә.
3. Стипендияне түләү елга бер мәртәбә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының агымдагы финанславы хисабына гпмәлгә ашырыла.
4. Стипендияне раслауга кандидатлар исемлеге Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең агымдагы уку елының бөтенроссия, республика, төбәк олимпиадалары йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы боерыклары нигезендә формалаштырыла.
5. Стипендия алуга Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре, шул исәптән Казан федераль университетының Алабуга институтының «Университет» гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, гамәлгә куючысы - Мәгариф министрлыгы һәм «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Алабуга Суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна гомуми белем бирү учреждениесе укчылары - бөтенроссия, төбәк, республика олимпиадаларында җиңүчеләр һәм призерлар кандидат була ала.
6. Кандидатлар исемлеге Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен бирү буенча комиссиягә фикер алышу өчен укучыларга - стипендиатлар расланучы мәктәп укучыларының бөтенроссия, төбәк һәм республика олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга тапшырыла.

7. Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләреннән стипендия алу өчен кандидатларны сайлап алуның гомуми критерийлары: 8 яшьтән алып 18 яшькә кадәр һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы раслаган мәктәп укучыларының бөтенроссия, төбәк һәм республика олимпиадалары нәтиҗәләре.

8. Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү өчен критерийлар укучыларга - бөтенроссия, төбәк һәм республика олимпиадаларында җиңүчеләргә, призерларга әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтасында китерелгән.

9. Стипендия күләме ел саен Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Алабуга муниципаль районы Советының бюджет турындагы карары белән билгеләнгән ассигнованиеләр күләме нигезендә билгеләнә.

10. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә стипендия алуга кандидатлар тәкъдим итү өчен «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенә агымдагы елның 30 апреленә кадәр түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

- әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә үтенечнамә;
- бөтенроссия, республика олимпиадалары дипломнары күчермәләре;
- бөтенроссия, республика олимпиадалары нәтиҗәләре турында боерыкларның күчермәләре;
- паспорт күчермәсе;
- Россия Федерациясе территориясендә салым органында физик затны исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсе (ИНН);
- мәҗбүри пенсия иминияте иминият таныклыгының күчермәсе.

Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе үтенечнамәне әзерли һәм имзалый.

11. Комиссия әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән 10 пунктта күрсәтелгән документлар буенча һәр кандидатура буенча фикер алышу уздыра һәм бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга стипендия билгеләү турында карар кабул ителә. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм «АМР мәгариф идарәсе» МКУнда өч ел дәвамында саклана.

Бөтенроссия, төбәк һәм республика
мәктәп укучылары олимпиадаларында
җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга
муниципаль районы Башлыгының
стипендиясен билгеләү турында
Нигезләмәсенә 1 нче кушымта

**Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләүгә критерийлар**

| № т/б | Катнашу нәтиҗәсе | Стипендия күләме |
|---|---|---|
| 1. | Бөтенроссия мәктәп укучылары фән олимпиадаларының йомгаклау этабында призлы урын алучылар | 20 000 |
| 2. | Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабында җиңүчесе | 10 000 |
| 3. | Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабы призеры | 7 000 |
| 4. | Республика олимпиадасының йомгаклау этабы җиңүчесе | 6 000 |
| 5. | Республика олимпиадасының йомгаклау этабы призеры | 4 000 |
| 6. | Татар теле буенча мәктәп укучыларының республика олимпиадасында җиңүче | 6 000 |
| 7. | Татар теле буенча мәктәп укучыларының республика олимпиадасы призеры | 4 000 |
| 8. | «Олимпка юл» республика олимпиадасының йомгаклау этабында җиңүче | 6 000 |
| 9. | «Олимпка юл» республика олимпиадасының йомгаклау этабы призеры | 4 000 |

Бөтенроссия, төбәк һәм республика
мәктәп укучылары олимпиадаларында
җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга
муниципаль районы Башлыгының
стипендиясен билгеләү турында
Нигезләмәсенә 2 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләүгә Бөтенроссия, региональ һәм республика укучылар олимпиадаларында җиңүче һәм призер булган укучыларга дәгъва кылучы турында мәгълүмат (белешмә)**

| (дәгъвачының фамилиясе, исеме, атасының исеме) | Туган көне (көн, ай, ел) | Йорт адресы, элемтә өчен телефон номеры | Уку йортының тулы атамасы | Дәгъвачының казанышларын күрсәтеп, кыскача характеристика |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе __________________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

имза

Мөһер урыны

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 3 июнендәге
753 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү буенча комиссия составы**

| **Фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Вазифасы** |
|---|---|
| Курамшин Н.Д. | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары |
| Балобанова А.С. | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазифаларын башкаручы |
| Тагирова Г.Р. | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе методисты, комиссия секретаре |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| Юшкова О.Е. | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең укыту бүлеге башлыгы |
| Әсләмова Г.Ф. | ТР АМР "1 нче гимназия-милли мәгариф үзәге" МБМУ директоры |
| Вегера В.Н. | ТР АМР «Инженерлык-технология лицее» МБМУ директоры |
| Гыйниятуллин Р.М. | ТР АМР "10 нчы күппрофильле лицей" МБМУ директоры |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 3 июнендәге
753 номерлы карарына
3 нче кушымта

**Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү комиссиясе турындагы Нигезләмә**

1. Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү комиссиясе Алабуга муниципаль районы (алга таба - Комиссия) башкарма комитеты карары белән расланa.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Бөтенроссия, төбәк һәм республика мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призерларга Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясен билгеләү комиссиясенең төп бурычлары кандидатларның документларын өйрәнү.

4. Комиссия Комиссия рәисе, аның урынбасары, Комиссия секретаре һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә. Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне аның рәисе башкара.

5. **Комиссия рәисе:**
- комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә;
- комиссия әгъзалары арасындагы вазифаларны бүлә;
- комиссия утырышларын уздыра һәм аларда рәислек итә;
- комиссия эшчәнлеген тәэмин итә торган карарлар кабул итә;

**Комиссия рәисе урынбасары:**
- ул булмаганда комиссия рәисе функцияләрен башкара;
- комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

Комиссия секретаре:
-утырышлар әзерләүне һәм уздыруны оештыруны гамәлгә ашыра

Комиссия, шул исәптән

- комиссия утырышларының протоколларын алып бара һәм аның карар проектларын рәсмиләштерә;

комиссия утырышына чакырылган затларга, экспертларга комиссия утырышының урыны,
вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә.

6. Комиссия утырышы агымдагы елның икенче кварталында уздырыла.

Комиссия утырышын комиссия рәисе, яки ул булмаганда комиссия рәисе урынбасары алып бара.

7. Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала;

Комиссия әгъзалары үз хокукларын өченче затларга, шулай ук Комиссия әгъзалары булган затларга тапшырырга хокукы юк.

Комиссия карарлары комиссиянең утырышта катнашучыларның ачык тавыш бирү юлы һәм күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм комиссия рәисе тарафыннан раслана.